РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
КОШКИ-НОВОТИМБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОШКИ-НОВОТИМБАЕВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 52-6-31, факс 52-6-31

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**11.11. 2020** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотибаево авыл җирлегенең Яңа Льяшево Пүчинкәсе торак пунктында, гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча, гражданнар җыенын билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, “Татарстан Республиксында җирле үзидарәләр турында”гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә **КАРАР КЫЛАМ:**

1. 2020 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбаево авыл җирлегенең Яңа Льяшево Пүчинкәсе торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарылачак мәсьәләне раслау:

“Сез, 2021 елга түбәндәге эшләрне, ягъни:

- Юл-урам челтәрен норматив халәткә китерү;
- Җәйге вакытта территорияләрдән куоъеллык үләннәр чабу эшләрен башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, балачактан инвалид, күп балалы гаиләләр һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбаево авыл җирлегенең Яңа Льяшево Пүчинкәсе торак пункты территориясендә яшәү урыны буларак теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан үзара салымга 1000 сум күләмендә акча җыелырга ризамы?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү йөкләнелә Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылган көненнән башлап үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге**
**Башлыгы** **С.В. Гаврилов**